КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 март г.Казань № 152

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау һәм аларга бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 17 апрель, 310 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25 май, 394 нче; 2020 ел, 17 апрель, 297 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1050 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы белән чиге уртак булган ике һәм аннан күбрәк Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру схемалары проектларын, Россия Федерациясе субъектларының территорияләрне планлаштыру

схемалары проектларын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территорияләрне планлаштыру документлары проектларын карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның алтынчы абзацында татар тестында «өлешендә» сүзеннән соң «, шулай ук махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләрен билгеләү өлешендә» сүзләрен өстәргә;

7.1 пунктның унынчы һәм унберенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм һәм алар һәлак булуны кисәтү, аларның яшәү мохитенең начараюын булдырмау чаралары булуга;

җирле әһәмияттәге объектларны урнаштырганда һәм төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрендә урнашкан торак пунктларның чикләрен билгеләгәндә төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләрен махсус саклау режимын үтәүгә;»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Министрлыкка килештерүче органның берсеннән генә территорияне планлаштыру документы проекты белән килешмәү турында бәяләмә кергәндә, Министрлык, территорияне планлаштыру документы проекты белән килешмәү турында бәяләмә әзерләү өчен нигез булып торган искәрмәләрне җайга салу максатларында, бу Тәртипнең 9 һәм 9.2 пунктларында билгеләнгән сроклар чыккан датадан 10 эш көне эчендә һәм бу Тәртипнең 9.1 пунктында билгеләнгән сроклар чыккан көннән 5 эш көне эчендә килештерү киңәшмәсен үткәрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин